КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 июль г.Казань № 591

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында муниципаль милектәге объектларны төзүне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрацияләү, техник яңадан җиһазландыру элементлары белән) финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләрен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 ел, 22 октябрь, 947 нче карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында муниципаль милектәге объектларны төзүне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрацияләү, техник яңадан җиһазландыру элементлары белән) финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында муниципаль ми-

лектәге объектларны төзүне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрацияләү, техник яңадан җиһазландыру элементлары белән) финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләрен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 ел, 22 октябрь, 947 нче карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында муниципаль милектәге объектларны төзүне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрацияләү, техник яңадан җиһазландыру элементлары белән) финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләренә, 5 пункттагы «Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан оештырылган юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең, капиталь ремонтлауның смета бәясен дөрес итеп билгеләүне тикшерү тәртибе турында» 2009 елның 18 маендагы 427 номерлы карары» сүзләрен «Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин